**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«25» октябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Төрнәс торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы;

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төрнәс т. п. юлларын салу, сезонлы карап тоту);

- Төрнәс торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (скважиналарны лицензияләүне) тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары өчен коелар);

- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (трактор өчен запас частьләр сатып алу, урамнарда агачлар җыештыру, авыл урамнарын төзекләндерү).

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В. Белов